Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:
а) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) – әйләнә-тирә мохитнең, шул исәптән табигать мохите компонентларының, табигый экологик системаларның торышына, аларда бара торган процессларга, күренешләргә комплекслы күзәтү, әйләнә-тирә мохит торышындагы үзгәрешләрне бәяләү һәм фаразлау;”;
б) утызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 статьяның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“дәүләт экология күзәтчелегенең бәйсезлеге;”;

3) 8 статьяның 1 өлешендә:
а) бишенче абзацта “әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын (дәүләт экология мониторингын)” сүзләрен “экология мониторингын (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын)” сүзләренә алмаштырырга, “күзәтүнең” сүзеннән соң “дәүләт экология мониторингының (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингының) бердәм системасы өлешен тәшкил итүче” сүзләрен өстәргә;

б) ундүртенче абзацта “экология контролендә” сүзләрен “экология күзәтчелегендә” сүзләренә алмаштырырга;

в) егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклауны) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеген һәм урманнарда федераль дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү;”;

4) 34 статьяның 3 пунктында “2001 елның 8 августындагы 128-ФЗ номерлы” сүзләрен “2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы” сүзләренә алмаштырырга, “җыю, куллану,”, “транспортировкалау,” сүзләрен төшереп калдырырга;

5) VIII кисәкнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“VIII КИСӘК
**ДӘҮЛӘТ ЭКОЛОГИЯ МОНИТОРИНГЫ (ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТНЕҢ ДӘҮЛӘТ МОНИТОРИНГЫ)**”;

6) 50 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“50 статья. **Дәүләт экология мониторингын (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын) гамәлгә ашыру**

1. Дәүләт экология мониторингын (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын) гамәлгә ашыру дәүләт экология мониторингының (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингының) бердәм системасы кысаларында дәүләт экология мониторингының (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингының) бердәм системасының ярдәмче системалары кысаларында күзәтчелек челтәрләрен һәм мәгълүмат ресурсларын булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) күрсәткечләренең дәүләт фондын төзү һәм аннан файдалану ярдәмендә федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан аларның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән компетенцияләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт экология мониторингын (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын) гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тиешле мониторингны гамәлгә ашыру барышында алына торган мәгълүматны дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) күрсәткечләренең дәүләт фондына җибәрергә тиеш.”;

7) 51 – 59 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

8) $135^2$ статьяның 2 өлешендә “әйләнә-тирә мохитне дәүләт тарафыннан мониторинглау” сүзләрен “дәүләт экология мониторингының (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингының)” сүзләренә алмаштырырга;

9) 144 статьяда:

а) исемендә “һәм контроль” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә “һәм контроль” сүзләрен төшереп калдырырга, “гамәлгә ашырыла” сүзләре татарча текстта үзгәрешсез кала;

в) 2 өлештә “һәм контроль” сүзләрен төшереп калдырырга, “гамәлгә ашырыла” сүзләре татарча текстта үзгәрешсез кала;

10) 164 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“164 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын зарарсызландыру һәм урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү**

Җитештерү һәм куллану калдыкларын зарарсызландыру һәм урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү “Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында” 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 6-ТРЗ